ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мортаза авылы торак пунктында,

Кырым-Сарай авыл җирлеге составына керүче

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы

2024 елның 22 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кырым-Сарай авыл җирлегенең Мортаза авылы торак пунктындагы гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының:

1. 2025 елда Баулы муниципаль районы Кырым-Сарай авыл җирлегенең Мортаза авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Кырым-Сарай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында бүтән яшәмәгән затлардан тыш, 300 (өч йөз) сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.өч ел, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән ирекле ярдәм һәм бурычларны үтәү турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләре (сво катнашучылары).
2. Алынган акчаларны:
   - Мортаза авылындагы юлларны карап тоту (чистарту, агызу);
   - Мортаза авылында зиратны төзекләндерү (киртәләр, төзелеш материаллары, урнаштыру, эшләү);
   - Мортаза авылында урам яктырткычларын ремонтлауга (электрик хезмәте күрсәтүгә).

Гражданнар җыенында рәислек итүче<br>Кырым-Сарай авыл җирлеге башлыгы Д. А. Шакирҗанов